КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 12 апрель г.Казань № 283

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 24 июль, 598 нче карары белән расланган «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 24 июль, 598 нче карары белән расланган «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә, 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Үзәкнең финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре түбәндәгеләр булып тора:

хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү һәм аларны матди бүләкләү;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү;

коммуналь хезмәтләр, бүлмәләрне, җайланманы, җиһазларны арендалау өчен

түләү;

транспорт һәм элемтә хезмәтләре күрсәтүне тәэмин итү;

оештыру техникасы, шәхси компьютерлар, сервер һәм челтәр җиһазлары сатып алу һәм карап тоту;

программа белән һәм мәгълүмати-аналитик тәэмин итү;

чыгым материаллары сатып алу;

уставтагы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруга башка чыгымнар.».

2. Бу карарның гамәле 2018 елның 20 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин